РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3540

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2027 елларга Әлмәт муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 2997 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 31 маендагы 390 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2027 елларга Әлмәт муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында»2024 елның 12 сентябрендәге 2997 номерлы карарына үзгәрешләрне кертергә:

«2024-2027 елларга Әлмәт муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру»муниципаль программасының 1 нче кушымтасында:

«2024 - 2027 елларга Әлмәт муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» таблицаларының "Коррупциягә каршы белем бирүне оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, граждан җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү коррупциягә каршы көрәш» 4 бүлегенең 4.4 пунктындагы «башкаручылар» баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы урынбасары; Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе (килешү буенча)»;

- «2024 - 2027 елларга Әлмәт муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары,

бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» таблицаларының «Коррупциягә каршы белем бирүне оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, граждан җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү коррупциягә каршы көрәш» 4 бүлегенең 4.5 пунктындагы «башкаручылар» баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча), район Советының кадрлар сәясәте бүлеге (килешү буенча), хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе (килешү буенча)».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларны башкаручы А.Р. Исхаков